# ЯШЕЛ БИШЕК

ТР ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘНГӘН МАХСУС КУШЫМТА

## Тугыз айда

САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

**Һәр өч ай саен Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы үз эшчәнлеге буенча исәп-хисап тота. Аның соңгысында министр Әгъләм Садретдинов түбәндәге мәгълүматларны игълан итте.**

✦ Иң пычрак һава Зеленодольск, Зәй, Алабуга, Бөгелмә, Нурлат һәм Казан кебек эре автомагистральләр үтүче шәһәрләрдә күзәтелгән.

✦ Министрлык Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә "Чиста һава - 2009" операциясе үткәргән. Аның барышында 7,5 мең автомашина тикшерү үткән. Шуларның 17 процентка якынында һавага зарарлы матдәләр чыгару нормаларга туры килмәгән.

✦ 9 ай эчендә министрлыкның дәүләт инспекторлары 300 дән артык предприятиенең су саклау законнарын үтәве мәсьәләсен тикшергән. Аның барышында ачыкланган 508 кагыйдә бозуның 342 се тиз арада юкка чыгарылган. 598 юридик һәм физик зат җаваплылыкка тартылган.

✦ Министрлык хезмәткәрләре 77 данә калдык сулар чистарту җайланмасының эшчәнлеген тикшергәннәр. Чисталыгын билгеләү өчен 340 урыннан су алынган.

✦ Тугыз айда экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссия 8 утырыш уздырган, шуның 6 сы күчмә утырыш. Ә берсе Дәүләт Советының экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты белән берлектә үткәрелгән.

✦ Быел 72,3 мең тонна каты көнкүреш калдыгы аралауга китерелгән һәм аннан 7,5 мең тонна икенчел чимал аерып алынган. Узган ел шушы вакыт эчендә 105,9 мең тонна каты көнкүреш калдыгы араланган һәм аннан 20 мең тонна икенчел чимал аерып алынган иде.

✦ План буенча республикада 324 биотермик чокыр төзелергә тиеш булган булса, төзелгән үләт базларының саны – 181. Бу – тиешленең 56 процентка якыны гына дигән сүз.

✦ Ел барышында түләмә авырулы терлекләр күмелгән 801 үләт базы бетон кәфен белән капланырга тиеш иде. Бу эш 96,2 процентка (771 данә) үтәлгән.

✦ Табигать байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану максатыннан 134 карьер тикшерелгән. Алексеевск, Әлмәт, Азнакай, Арча, Бөгелмә, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Лениногорск, Мамадыш, Мөслим, Чирмешән, Нурлат, Яңа Чишмә районнарында "кыргый" карьерлар аеруча күп.

✦ Сентябрь аенда министрлык республиканың иҗтимагый экологик хәрәкәте белән берлектә "Автомобильсез бер көн" акциясе үткәрде. Анда 54 мең кеше катнашты. Бу – республикада теркәлгән автомобиль хуҗаларының 6 проценты.

✦ "Автомобильсез бер көн" Чаллы, Түбән Кама, Кукмара муниципаль районнарында һәм башкаланың Киров районында аеруча актив оештырылды. Әлеге чарада Яшьләр эше, спорт һәм туризм министрлыгы коллективы үрнәк күрсәтте.

✦ Исәпләүләргә караганда, бер көн эчендә атмосфера һавасы 3,9 мең тоннага, шул исәптән кислород 564 тоннага азрак исраф ителде.

✦ Һавага сөрем газы 108 тонна, азот диоксиды 59 тонна, углеводород янудан калган башка продуктлар, шул исәптән аеруча зарарлы бензоперин газы 43 тоннага кимрәк чыгарылды.

# Көньяк-көнчыгышта үзгәрешләр азмы әллә?

КОМИССИЯ ЭШТӘ



*Наил Гамбәрович Мәһдиев, Бөгелмә шәһәр һәм район администрациясе башлыгы*




**Экологик куркынычсызлык һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышы Бөгелмә шәһәрендә узды. Анда нефть төбәгендәге әйләнә-тирә мохитнең торышы каралды. Моннан бер еллап элек әлеге регионлдагы экологик хәлләр бер тикшерелгән иде инде.**

### Су

Бөгелмәдә сәнәгать предприятиеләре гаять күп. Алар бүген бар көченә эшли. Шуңа күрә эшсезлек проблемасы юк диярлек. Шәһәрдә күп катлы йортлар, яңгырдан соңгы гөмбәләр шикелле, бер-бер артлы калкып кына тора. Бүген биредә туксан меңнән артык кеше яши.

Әле кайчан гына бөгелмәлеләр өчен эчәр суның сыйфатсызлыгы борчу тудыра иде. Алар, 70-80 елларда төзелгән су җыйгычыннан җибәрелгән Кама суы гигиена-санитария таләпләренә җавап бирми, дип чаң суктылар. Андагы фенол, нефть калдыклары кеше сәламәтлегенә зыян салуын белгечләр дә инкарь итмәде.

1996 елда "Чиста су" программасы эшләнде һәм шуны тормышка ашыру нәтиҗәсендә "Коногоровка-Вязовка-Бөгелмә" су суырту станциясе барлыкка килде. Хәзер бөгелмәлеләр бары тик җир асты һәм чишмә суларыннан гына файдалана. "Бөгелмә-Водоканал" оешмасы башлыгы Мирфаяз Кашапов сүзләренә караганда, су суырту корылмасын сафка бастырганнан бирле эчә торган суның сыйфаты 7,7 тапкырга яхшырган, ә бәясе ун процентка кимегән.

– Шәһәрне генә түгел, тирә-як бистәләрне дә су белән тәэмин итәбез. Кама суыннан баш тарту нәтиҗәсендә эчәк инфекциясе, яман шеш ише чир белән интегүчеләр саны кимеде, – ди Мирфаяз әфәнде.

### Чүп

Көньяк-көнчыгыш регионга, Бөгелмәдән тыш, Нурлат, Лениногорск, Әлмәт һәм Чирмешән районнары да керә. Экология һәм табигый байлыклар министрының беренче урынбасары Марат Мәһдиев сүзләреннән аңлашылганча, биредә җир өсте суларын савыктыруга игътибарны арттырырга кирәк. Аларга ташлана торган җыентык суларның күләме узган ел чамасында калган. Соңгы биш елда сафка бастырылган чистарту җайланмалары эшчәнлеге нәтиҗәсендә елгаларга әләгә торган нәҗес сулар 12,5 процентка кимү турында рәсми мәгълүматлар бирелсә дә, Көньяк-көнчыгыштагы елга-күлләрнең суы чиста дип исбатлавы кыен.

– Бүген республикадагы чистарту җайланмаларының нәтиҗәлелеге 40-90 процент чамасы. Ә Көньяк-көнчыгыш төбәктәгеләрнеке аннан да түбәнрәк, – ди Марат Мәһдиев.

Тирә-якны чүп-чардан, каты көнкүреш калдыкларыннан чистарту, аларны аралау мәсьәләсе ведомствоара комиссия утырышларының һәрберсендә күтәрелмичә калмый. Бу хакта күп сөйли торгач, байтак кына районнарда чүп аралау җайланмалары корылды. Быел, мисал өчен, Апас, Актаныш, Саба, Балтач, Менделеев һәм Алексеевск районнарында калдык эшкәртә торган алты цех ачылган. Ни гаҗәп, Нурлатта андый чүп аралау линиясе юк. Биредә кешеләр чүпне кул белән аралый. Ә менә Чирмешәндә мондый механик җайланма узган ел сафка баскан. Әллә ни табыш алырга өлгермәсәк тә, файдасын сизәбез, дип сөйли чирмешәнлеләр. Икенчел чималны Чаллыга, Самарага илтеп тапшыралар икән.



Әлмәтлеләр исә чүп җыю өчен мәйданчыклар төзеп, шунда 13 бункер куйганнар. Ләкин соңгы вакытта 1996 елдан бирле эшләп килә торган каты көнкүреш калдыклары полигоны проблемалыга әверелгән. Шешәләрнең бәясе төшү сәбәпле, аларны җыеп тапшыруның мәгънәсе калмаса, Самарада исә чүпрәк-чапрак җыюны бөтенләй дә туктатканнар.

– Шул сәбәпле араланмаган калдыклар полигоннарга китерелә. Бу исә икенчел чимал буларак файда китерә алырдай 90 процент калдык әрәм-шәрәм була дигән сүз. Полигоннарның бик тиз тулу сәбәбе менә шунда, – дип нәтиҗә ясый Марат Фаикович. – Югыйсә бүгенге мөмкинлекләр ярдәмендә калдыкларны аралап җыярга да, эшкәртергә дә була. Сәнәгать тармагы калдыкларының – илле, хәтта сиксән процентын икенчел чимал буларак файдаланырга мөмкин. Җыела торган барлык каты көнкүреш калдыкларының дүрттән бер өлеше әле тагын нәрсәгә дә булса яраклы, – ди министр урынбасары.

Хикмәт чүп-чарны эшкә яраклы итүдә генә дә түгел бит әле. Шул ук полигоннарда көн-төн череп ятучы чүпрәк-чапрак өемнәреннән күпме зарарлы газ күтәрелә. Ә бит бу якның һавасы аннан башка да мактанырлык түгел. Бүген регионда атмосферага пычрак матдәләр бүлеп чыгаручы тугыз меңнән артык чыганак барлыгы билгеле. Әмма аларның нибары алты проценты гына газ һәм тузанны тотып кала торган махсус җайланмалар белән тәэмин ителгән. Боларның мөмкинлеге һавага чыгарыла торган пычрак матдәләрнең өчтән берен генә зарарсызландырырга җитә. Моннан тыш әлеге төбәктә автомобильләрнең күбәюе шулай ук һаваның савыгуына илтми. Машиналар бүлеп чыгарган газ күләме елына 60 тоннага кадәр җитә яза.

### Юл

Көньяк-көнчыгышны урманнарга бай дип әйтеп булмый. Бу якта урман полосаларын да еш очратмыйсың. Аның каравы транспортның исәбе-хисабы юк. Менә шуңа күрә дә ведомствоара комиссия утырышында транспорт һәм юл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Павел Чернов агымдагы елда 55 мең чакрымга яшеллек полосасы утыртылырга тиеш дип саный.

– Яшеллекнең әйләнә-тирә мохитне савыктыруда да әһәмияте зур, – ди ул. – Беренчедән, агачлар ягулыктан бүленеп чыга торган авыр металл тозларына юл буеннан ары китәргә ирек бирми. Икенчедән, урман полосалары җил һәм эрозиягә каршы торучы ролен дә әйбәт башкара.

Әмма юлчылар юл буендагы агач-куаклыкларны бөтенләй башка максатларда файдалана. Анда чүп-чарның нинди генә төре юк. Хәер, юл буйларын да чиста дип әйтеп булмый. Министр урынбасары әйткәнчә, андагы ташландык чүп-чар күләме елына 6,5-7 мең (!) тоннага кадәр җитә икән. Агымдагы елның ноябрь аена кадәр автомобиль юллары буеннан ике мең тоннадан артык чүп җыеп алынган.

Хәзерге вакытта трасса буйларында АЗС, ял урыннары, ашханә, кунакханә ише алты йөздән артык халыкка хезмәт күрсәтү объекты бар. Әмма аларның биш йөздән артыгы тиешле кагыйдәләргә җавап бирми. Күбесендә тизлекне киметә торган юл полосалары каралмаган, автобуслар өчен махсус туктап тору урыннары, чүп җыю җайланмалары, бушлай бәдрәфләр юк. Булганнары да санитария-гигиена таләпләрен үтәми.

**Чулпан ХӘЙРУЛЛИНА**

# Уңның нишләгәнен сул белми

ХАТ

**Казанның Чуйков урамында яшәүчеләр үз йорт тирәләрен үзләре яшелләндерә.**

Гаврилов урамыннан алып Адоратский урамына кадәр сул яктан 64, 66 нчы йортларның хуҗалары, уң яклап 73, 75, 85, 93 нче йортларда яшәүчеләр агач утыртты. Унсигез ел эчендә әлеге агачлар зур булып үсте.

Үткән ел Чуйков урамына асфальт түшәгәндә, үзгәрешләр кертәбез дип, зифа буйлы кырыклап агачны кисеп ташладылар. Ә быел көзен, 85 нче йорт каршындагы канализация базын күмдерү өчен чакырылган экскаваторга эшләр өчен урын кирәк, дигән сылтау белән тагын 18 агачны кисеп ыргытмасыннармы! Шул чокырдан ерак түгел икенчесе барлыкка килгәч, халык аптырап ук калды. Бу юлы күпме агачның башына җитәрләр икән? Әле бит боларга хәтле дә "Горводзеленхоз" хезмәткәрләре ике ел элек 10 агачны кисеп киткәннәр иде.

Яшеллеккә безнең районда менә шундый һөҗүм бара. Бу эшләр өчен бер җитәкченең дә җавап тотканы юк. Эшләрен башкарып киткәч киселгәннәре урынына яңалары утыртылыр дип күпме көтсәк тә юкка гына. Яшеллекне яклаучылар юк дәрәҗәсендә. Булганын да сакламыйлар. Бездә, гомумән, уң кулның нәрсә эшләгәнен сул кул белми кебек. Казанда 2013 елда халыкара Универсиада узачак. Меңләгән спортчылар һәм туристлар киләчәк. Шәһәрнең матурлыгы аның яшеллегенә дә бәйле. Димәк, Универсиадага башкаланы яшелләндерү буенча махсус программа кирәк.

**Рафаэль САЛЬМУШЕВ**

# Кем пычрата, кем чистарта...

## Базарлы Матакта 26 гектарлы буа корылды

**Предприятиеләрнең нинди генә төрен алма, аларның барысы да әйләнә-тирә мохиткә зыян салып эшли.**

Ә менә мелиорация белән шөгыльләнүчеләр артыннан табигать, нигездә, ямьләнеп кала. Әлки механикалаштырылган күчмә колоннасы (МКК) "Мелиорация" ачык акционерлык җәмгыяте башкарган эшләр турында фәкать шундый бәя генә биреп була.

1990 еллар уртасына тәмам юкка чыгу алдына китереп терәтелгән колоннага моннан нәкъ 10 ел элек җитәкче булып Әнвәр Сәлимҗан улы Мәрдиев билгеләнгәч, предприятие икенче сулышка күчеп эшли башлады. Шул гомердән бирле әлеге предприятие Әлки, Спас һәм Яңа Чишмә районнарында дистәләгән буалар, сусаклагычлар төзеп өлгергән. Аларның барысы да әйләнә-тирәгә үзенчәлекле ямь биреп тора. Анда балыклар гына үрчеми, киек кошлар да иркенлектә бала чыгара, халык хозурланып ял итә.

Быел исә Әлки МККсы Базарлы Матакның көньяк-көнчыгыш өлешендә зурдан кубып мул сулы буа корып куйды. 26 гектар мәйданга җәелгән буага су Актайга кушылучы инештән килә һәм кар сулары белән бергә анда 600 мең кубометр җыелачак. Бу эшләрдә быел Россия мелиорация су хуҗалыгының Идел буе округы буенча үткәрелгән бәйгеләрендә җиңеп чыккан бульдозерчы А.Романов, икенче урын алган экскаваторчы Ф.Гыйләҗев, эретеп ябыштыручы Н.Бушков, Ә.Әгъләмов шикелле уңганнар аеруча зур тырышлык күрсәтәләр. Хәер, предприятиенең башка эшчеләре дә хезмәттә кимен куймый, һәммәсе сәгать механизмындагы детальләр шикелле үз эшен белеп, җиренә җиткереп башкара. Шулай булганга нибары 50 кешедән торган коллектив быелның 10 ае эчендә 15 миллион сумлык эш башкарып өлгергән.

Әлки МККсы бер Базарлы Матак буасын төзү белән генә шөгыльләнми, билгеле. Ул район үзәгендәге каты көнкүреш калдыклары полигоны өчен чүп түгү казанлыгының икенче чираттагысын ясый, Чуаш Кичүе авылындагы 4 кипкән күлне чистартып тирәнәйтә, Сихтермә - Хузангай авылында агучы Инча елгасына буа корып куя, Актай елгасының Карга авылы эченнән агучы өлешен турылата.

Күренә ки, әлеге эшләрнең барысы да, икътисадый файданы күздә тоту белән бергә, табигать - анабызның йөзен тагын да сафландыру, чистарту максатыннан чыгып башкарылган.

**Шәһит ГАТАУЛЛИН**

# Гадәтең нинди, тормышың шундый

ГАЛИМНӘР РАСЛЫЙ




**Узган гасырда яшәп дөнья куйган әби-бабайларны кире үз халәтенә кайтарсаң, бүгенге тормыш турында ни әйтерләр иде икән? Өлкән кешеләрдән мондый сүзләрне еш ишетергә туры килә. Су ташыйсы, кер юасы юк. Хәтта камырны да кибеттән сатып алабыз. Әмма бер яхшының бер яманы дигәндәй, яшәү шартлары яхшырган саен табигатькә зыян да арта бара. Шуңа да экологик куркынычсызлык дигән гыйбарә бүген күпләрнең аңына үтеп керде. Күптән түгел "Экология: яшәү сыйфаты" дигән темага узган "түгәрәк өстәл" артындагылар да, башлыча, гел шул хакта сүз алып барды.**

Гомер озынлыгы, колак ишетмәгән чирләр, баласызлык – бу проблемаларның барысын да диярлек экология белән бәйләп аңлатырга тырышалар. Ә рекламчыларга исә шул гына кирәк. Кибет киштәләрендә "Экологик яктан чиста продукт" дип тамгаланган товарлар буа буарлык. Азык-төлектән алып экологик яктан "куркынычсыз" музыкага кадәр сатып алырга мөмкин. Чынлыкта исә:

– Бездә "Экологик яктан куркынычсыз продукт" дигән бренд юк. Бу кеше аңын томалау гына, – ди "Тест-Татарстан" федераль идарәсененең (ФГУ) стандартлаштыру һәм экологик менеджмент буенча бүлек башлыгы Владимир Бармин.

Россиядә шул рәвешле кешене алдый торган билгеләмәләр күбәеп китте, чөнки бүген кулланучы чыннан да экологик яктан чиста товарга мохтаҗ, ди белгеч. Аның сүзләреннән аңлашылганча, пиар осталары нинди генә юлларга бармыйлар, хәтта ялган грамоталарга кадәр уйлап табалар. Белгеч фикеренчә, нинди генә сертификат уйлап табылмасын, кешенең яшәү рәвешен яхшырту, сыйфатны көчәйтү өчен бу аз булачак. Биредә дәүләт күзәтчелеген арттыру зарур, ә анысы исә әлегә оештырылып бетмәгән.

– Кибеттә сатыла торган шешәле суларның берсе генә дә җитәрлек дәрәҗәдә микроэлементлар белән баетылмаган. Ә тышындагы язуда организм өчен кирәкле матдәләрне тезепме-тезәләр, – ди КДМУ аспиранты Наилә Дәүләтова. – Теге яки бу исемдәге суны ни өчен сатып алалар? Безнең тикшеренүләр шуны күрсәтә: сатып алучыларның ун проценты дуслары киңәшеннән чыгып эш итә, 11 проценты консультант сүзенә ышана, 23 проценты эчке тоемлавына өстенлек бирә. Чынлыкта исә товарны тәкъдим иткән бәяләмәнең нибары өч проценты гына дөреслеккә туры килә. Ә менә 56 проценты– тулаем реклама.

Әлеге очрашуда белгечләр тормыш сыйфатын ачыклау буенча да озак кына бәхәсләштеләр. Техник фәннәр кандидаты, "МОС" журналы редакторы Олег Розенталь әйтүенчә, бездә кулланыла торган җайланмаларның берсе дә йөз процент төгәллек белән эшләми.

– Әйтик, суда булган төрекөмеш күләмен билгеләүче җайланма яртылаш ялгыша. Моны норма дип кабул итәләр, – ди Олег Моисеевич.

Татарстанның экология һәм табигый байлыклар министры урынбасары Анатолий Щеповских исә әйләнә-тирә мохит һәм сәламәтлек мәсьәләләрендә оптимизмын югалтырга уйламый.

– Игътибар үзәгендә булырга тиешле зоналар бар, әлбәттә, – ди ул. – Ләкин алар барысы да ныклы күзәтү астында. Бүген сәнәгать тармагы калдыкларын табигый юл белән зарарсызландыру тормышка ашмаслык хыял түгел. Без соңгы елларда аларның күләмен берникадәр киметүгә ирешә алдык. Киләчәктә дә калдык күләмен арттырмау төп максатларның берсе булып калачак.

Белгечләр, куркыныч янаган табигый зоналарны аерым күзәтү астына алырга кирәк, дигән фикерне алга сөрде. Бүген андый объектлар саны инде ике йөзгә җитеп килә икән. 2006 елда дөнья күргән Кызыл китап буенча нәтиҗә ясаганда элегрәк югалуга таба киткән кайбер үсемлекләр хәзер үрчи башлаган.

КДМУ профессоры Анатолий Иванов исә тормыш сыйфаты кешенең яшәү рәвешенә бәйле дигән караштa тора. Аның фикеренчә, тирә-як мохит кеше тормышына нибары 20-30 процент очракта гына йогынты ясый. Нәселдән, геннардан килә торган факторлар 10-12 процентка үзен сиздерергә мөмкин. Кешенең тормыш сыйфаты яртылаш аның яшәү рәвешенә, гадәтләренә бәйле. Начар гадәтләрнең нәтиҗәсе иртәме-соңмы бәреп чыга.

– Республикада спорт белән шөгыльләнү, дөрес туклану, сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шартлар тудырыла. Халыкны эш, хезмәт хакы белән тәэмин итү юнәлешендә дә эш алып барыла, – дип раслый профессор. – Шуның нәтиҗәсендә 2005 елда яңа туган балалар арасында бер мең балага 8 үлем очрагы туры килсә, 2008 елда бу күрсәткеч алтыга гына калды. Гомер озынлыгы 67,9 яшьтән 69,4 яшькә кадәр озынайды. Ул тагын да озынрак булсын дисәк, начар гадәтләрне ташларга кирәк.

**Чулпан ХӘЙРУЛЛИНА**

# Бер атнада 509 бозу

ХӘБӘР

Узган атнада экологик милиция хезмәткәрләре экология һәм шәһәрне төзекләндерү буенча 509 административ кагыйдә бозу очрагы теркәделәр. Шуның 395 е муниципаль районнар һәм шәһәрләрдә алып барыла торган төзекләндерү эшләренә бәйле. Бигрәк тә Казан һәм аның тирә-юне, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Алабугада тиешле кагыйдәләр үтәлми.

Тәртип бозуларның 11 очрагы үз белдекләре белән җир басып алудан гыйбарәт. Сулыкларны саклау кагыйдәсен бозган өчен бер оешма административ җаваплылыкка тартылган. 39 оешма тышкы мәгълүмат чыганакларын урнаштыруда гаепле дип табылган. 38 сәүдә предприятиесе сәүдә кагыйдәләрен бозуда гаепләнгән.

Ekol-004.p65 1 01.12.2009, 21:00